ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2018 ел, 7 ноябрь №1615

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 14 сентябрендәге 1337 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы территориясендә шәһәр яны маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж алып баруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарны каплау максатларында пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Лениногорск муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны җайга салу һәм идарә итү системасын оештыру һәм камилләштерү максатларында «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 14 сентябрендәге 1337 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы территориясендә шәһәр яны юлларының муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне һәм өстәмәне кертергә:

1 пунктта түбәндәге эчтәлекле 1.3 пунктча өстәргә:

«1.3.2018 елга субсидияләрнең иң чик суммасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бюджетында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә чыгым йөкләмәләрен финанслау өчен каралган финанс чараларыннан, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 06 июлендәге 1640-р күрсәтмәсе белән расланган чикләрдә Татарстан Республикасы бюджетының финанс чараларыннан түзелә.»;

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы территориясендә шәһәр яны юлларының муниципаль маршрутлары буенча җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында ташучыларга субсидияләр бирү комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: комиссия составыннан: Ухова О.П.; комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Иванова Гөлназ Альберт кызы - "Лениногорск муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Советы Аппаратының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы.

3. Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында

урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Н.Р.Залаков

М.Г. Якупов 5-15-41